**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

# КАРАР

№ 12 18.12.2015ЕЛ.

Аксубай муниципаль районының 2016 елга бюджеты турында

Аксубай муниципаль районының финанс бюджет палатасы рәисе О. П. Сетрова докладын тыңлаганнан соң һәм 2016 елга Аксубай муниципаль районы бюджеты проектын караганнан соң, Аксубай муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1 Пункт

1. 2016 елга Аксубай муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Аксубай муниципаль районы бюджеты керемнәренең гомуми күләме 580355,66 мең сум;

2) Аксубай муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 580355,66 мең сум. 3)Аксубай муниципаль районы бюджеты кытлыгының чик күләме 0 мең сум.2.Әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә 2016 елга Аксубай муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын билгеләү;

2 нче Пункт

1. 2017 елның 1 гыйнварына Аксубай муниципаль районының бурыч йөкләмәләре буенча Эчке муниципаль бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә билгеләргә.

2. 2016 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының муниципаль бурычының чик күләмен 0 мең сум күләмендә билгеләргә;

3 Пункт

Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә 2016 елга фаразланган керемнәр күләмен Аксубай муниципаль районы бюджетында исәпкә алырга

4 нче Пункт

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 60.1 статьясындагы 2 пункты нигезендә әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә 2016 елга Аксубай муниципаль районы бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативларын расларга.

5 Пункт

1. Әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә Аксубай муниципаль районы бюджеты – Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә органнары керемнәренең Баш администраторлары исемлеген расларга.

2. Әлеге карарның 5 нче кушымтасы нигезендә Аксубай муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеген расларга.

6 Пункт

1. Әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә 2016 елга бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре төркемнәренә (Аксубай муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программалы булмаган юнәлешләре) бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары (дәүләт һәм муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программалы булмаган юнәлешләре), бюджет ассигнованиеләрен бүлүне расларга;

2. Әлеге карарга № 7 кушымтасы нигезендә 2016 елга Аксубай муниципаль районы чыгымнарының ведомство структурасын расларга;

3. 2016 елга максатчан статьяларга (Аксубай муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программалы булмаган юнәлешләренә), чыгымнар төрләре төркемнәренә, бүлекләргә, әлеге карарның 8 нче кушымтасы нигезендә 2016 елга бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекчәләренә бюджет ассигнованиеләрен бүлүне расларга.

4. 2016 елга гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2850 мең сум күләмендә расларга,

7 нче Пункт

2016 елга җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен әлеге карарның 9 нчы кушымтасы нигезендә бүлү белән 37069,6 мең сум күләмендә расларга.

8 нче Пункт

2016 елга җирлекләр бюджетларының баланслылыгын тәэмин итү чараларына җирлекләр бюджетларына дотацияләр күләмен әлеге карарның 10 нчы кушымтасы нигезендә бүлү белән 547,3 мең сум күләмендә расларга.

9 Пункт

2016 елга Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күләмен әлеге карарның 11 нче кушымтасы нигезендә бүлү белән 24 мең сум күләмендә расларга.

10 нчы Пункт

2016 елга хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күләмен әлеге карарның 12 нче кушымтасы нигезендә бүлү белән 1470,5 мең сум күләмендә расларга.

11 нче Пункт

«Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итүче Фонд турында» 21.07.2007 елдагы 185-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү һәм торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итүче Фонд чаралары хисабына финанс ярдәме алу өчен Аксубай муниципаль районы бюджетында исәпкә алырга:1)2016 елда күпфатирлы торак йортларны капиталь ремонтлау буенча чараларны тәэмин итүгә район бюджетына Аксубай ш .т. п. бюджетыннан тапшырыла торган бюджетара трансфертлар, төзелгән килешү нигезендә 1289 мең сум күләмендә.

1) «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 07.12.2011 ел, № 6-ФЗ Федераль законны үтәү йөзеннән Аксубай муниципаль районы бюджетында исәпкә алырга

2016 елга җирлек бюджетларыннан район бюджетына тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыруга тапшырыла торган бюджетара трансфертлар, төзелгән килешүләр нигезендә, әлеге карарның 13 нче кушымтасы нигезендә 270,8 мең сум күләмендә.

Тиешле җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына әлеге пунктта күрсәтелгән бюджетара трансфертларны кертергә һәм 1 апрельгә кадәр (бюджетара трансфертларның еллык күләменең 1/2 өлешеннән дә ким булмаган) һәм 1 октябрьгә кадәр (бюджетара трансфертларның калган өлеше) ике өлеш белән күчерүне тәэмин итәргә.

12 нче Пункт Әлеге карарның 14 нче кушымтасы нигезендә 2016 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган бюджетара трансфертларны Аксубай муниципаль районы бюджетында 400460,26 мең сум күләмендә исәпкә алырга.

13 нче Пункт 2016 елга Аксубай муниципаль районы Юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 16135,6 мең сум күләмендә расларга һәм аларны 2016 елга Аксубай муниципаль районының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасы чараларын тормышка ашыруга юнәлтергә.

14 нче Пункт 1. 2016 елда Аксубай муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына бюджет кредитлары бирелми дип билгеләргә .

15 нче Пункт

1. Аксубай муниципаль районы муниципаль хакимият органнары 2016 елда муниципаль хезмәткәрләр һәм бюджет өлкәсендәге учреждениеләр һәм башка оешмалар хезмәткәрләре санын, шулай ук аларны тотуга киткән чыгымнарны арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

2. 2016 елда җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына муниципаль хезмәткәрләр һәм бюджет өлкәсендәге учреждениеләр һәм башка оешмалар хезмәткәрләре санын арттыруга китерүче карарлар кабул итмәскә тәкъдим итәргә.

16 нчы Пункт 1. Аксубай муниципаль районы бюджеты акчалары калдыклары Аксубай муниципаль районы исеменнән төзелгән товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өчен төзелгән муниципаль контрактлар өчен түләүгә файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә 2016 елда әлеге муниципаль контрактлар шартлары буенча тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә максатлар Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта.

Әлеге карар белән расланган керемнәрдән тыш, Аксубай муниципаль районы бюджетын башкарганда алынган субсидияләр һәм субвенцияләр әлеге карарга үзгәрешләр кертмичә, җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертмичә, субсидияләр һәм субвенцияләр бирү максатларына туры китереп чыгымнарны арттыруга җибәрелә.

17 нче Пункт Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Аксубай муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләр башкара.

18 нче Пункт Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм билгеләнгән тәртиптә имзаланганнан соң 10 көннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

19 нчы Пункт Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Аксубай муниципаль районының бюджет, салымнар һәм финанслар, җирле җыемнар, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,
СоветРәисе К.К.Гилманов